Татарстан республикасы Сарман муниципаль районы
муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе
«Зиннәт Хәсәнов исемендәге
Иске Кәшер урта гомуми белем бирү мәктәбе»

| | | |
|---|---|---|
| Каралды<br>1 нче номерлы ММО утырышында<br>16.08.2021ел | Килешенде<br>Мәктәп директорының тәрбия эшләре буенча урынбасары<br>_________ Р.З.Рамазанова<br>17.08.2021 ел | Расланды<br>Мәктәп директоры<br>_________Р.Г.Ахметбаева<br>18.08.2021ел |

# Мәктәпкәчә белем бирү төркеменең 2021-2022 нче уку елына эш планы

Иске Кәшер,
2021 ел

## 2020-2021 уку елына укыту-тәрбия эшенә анализ.

2020-2021 нче уку елында балаларга тәрбия-белем бирү эше үз югарылыгында алып барылды, еллык план буенча эшләнәсе эшләрнең үтәлде.

Мәктәпкәчә төркем ел буе балаларга эзлекле белем бирү, физик яктан чыныккан, сәламәт, табигатьне саклый белүче балалар тәрбияләү бурычлары өстендә эшләде. Белем һәм тәрбия бирүнең беренче баскычы булган мәктәпкәчә тәрбия бирү учреждениеләренең эшен нәтиҗәле итү өчен яңа идеяләр, белем-тәрбия бирүдә инновацион технологияләр кулланылды.

Төркемдә балаларның физик, интеллектуаль һәм шәхси үсешен тәэмин итү, иҗат мөмкинлекләрен ачу һәм үстерүгә нык игьтибар ителде. Тәрбияче тарафыннан балалар бакчасының укыту-тәрбия планнары, шөгыльләр челтәре һәм календарь планнары төзелде, педагогик киңәшмәдә килешенде һәм гамәлгә кертелде. Ел дәвамында шул расписание буенча тәрбияче даими рәвештә балалар белән шөгыльләр алып барды. Мәктәпнең башлангыч сыйныф укытучылары белән ныклы элемтәдә торабыз: алар елга берничә тапкыр мәктәпкәчә төркемгә шөгыльләр карарга киләләр, гомуми киңәшмәләрдә, ата-аналар җыелышларында катнашалар.

Балаларының сәламәтлеген саклау, ныгыту хәзерге көндә ата-аналарны, педагогларны иң борчыган мәсәләләрнең берсе. Шуннан чыгып үз алдыбызга түбәндәге мәсьәләләрне куйдык:

- хәрәкәт - бала өчен иң кирәкле шарт булуын күз уңында тотып, бакчада хәрәкәтле уеннарны үз югарылыгында уздыру;
- туклану - бала организмы өчен иң мөһиме шарт, шуңа күрә менюны сәламәтлекне саклау технологиясенә нигезләнеп төзү;
- организмны чыныктыру нәтиҗәсендә баланың салкынга, эссегә, авыруларга каршы торучанлыгын арттыру, чыныктыруны һәр баланың үзенчәлекләрен искә алып оештыру;
- балаларның бакчадан тыш вакытын дөрес оештыру буенча ата-аналар белән әңгәмәләр үткәрү;
- мәктәпкәчә яшьтәге балачак - сабыйның психик үсешендәге беренче чор, чөнки бу яшьтә шәхеснең бөтен психик сыйфатларына һәм үзенчәлекләренә нигез салына, шуларны истә тотып, баланың һәрьяклап үсеше өчен гаиләнең тәрбияче белән үзара аңлашып, ярдәмләшеп эшләвен булдыру.

Кыскасы, балаларны сәламәт рухта тәрбияләү – балалар бакчасының изге бурычы, чөнки балаларның күп вакыты бакчада уза, ул аларның икенче өе булып тора. Шунлыктан төркемдә нәниләр өчен барлык уңай шартларны

тудырырга тырыштык. Балаларның сәламәтлеген саклау, ныгыту, аларның физик һәм интеллектуаль үсешен тәэмин итү йөзеннән, эшебезне планлаштырудан башладык, планнарны балалар бакчасының эшен камилләштерү буенча үзгәрешләр кертеп һәм яңа бурычлар куеп оештырдык. Район педиатры тарафынан балаларны тикшерү үткәрелде. Иртәнге гимнастика, физкультура занятиеләре ел буена программага нигезләнеп, тиешле дәрәҗәдә алып барылды. Физкультура дәресләрендә иң беренче балаларның активлыгына игътибар ителде, яңалыклар кулланылды.

Төркемдә физкультура эшчәнлеге атнага өч тапкыр уздырылды - дәреснең берсе, һава торышы уңай булганда, ачык һавада узды. Эшчәнлек түбәндәге мәсьәләләрне тормышка ашырдык:

- балаларның үсешенә һәрвакыт игътибарлы булу;
- балаларга тормышта кирәкле хәрәкәт күнекмәләре бирү;
- сәламәтләндерү, чыныктыру эшенә шартлар булдыру;
- балаларның сәламәтлекләрен ныгыту, көчен, җитезлеген үстерү;
- сәламәтләндерү юнәлешендә төрле физик күнегүләр белән даими шөгыльләнүгә ихтыяҗ булдыру;
- заман таләпләренә туры килгән программалар куллану, яңалыкка омтылу.

Грипп эпедимиясе вакытында бакча карантинга ябылмады, авыручы балалар саны да аз булды. Бакчада ел буена көндәлек режим төгәл үтәлде, йоклар алдыннан аяк кулларны юу, йокыдан торгач балаларның күңелен күтәрү, чыныктыру күнегүләре эшләтелде. Төркемдә буш вакытларда даими рәвештә күз гимнастикасы, аваз әйтү гимнастикалары кертелде. Ел дәвамында дезинфекция чаралары күрелде.

Чыныктыру, сәламәтләндерү процедураларын башкарганда түбәндәге гигиена шартлары һәм таләпләре үтәлде:

- бүлмә һавасының саф булуы;
- бинадагы һава температурасының нормада булуы;
- киемнәрнең һава температурасына карап дөрес сайлануы;
- актив хәрәкәт режимы.

Бу юнәлештәге эшнең нәтиҗәсе ата-аналардан да бәйле. Без аларга сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру принципларын өй шартларында да үтәү кирәклеген искәртеп тордык.

Менюда ризыклар төрләндерелде, балалар аксымга бай продуктлар, үз бакчабызда үстерелгән яшелчә, ел әйләнәсендә җиләк-җимеш белән тукландырылды.

Дөрес туклану, көндәлек режимны, физкультура, спорт белән даими шөгыльләнү, организмны чыныктыру балаларыбыз сәламәтлегенә уңай тәэсир итте.

Һәр ел фасылын зур оешканлык белән каршы алдык. Язын тирә-якны чистартып, апрельдә чәчәк үсентеләре утыртып каршыладык. Бакчадагы язгы эшләр белем-тәрбия бирү эшләре белән чиратлап алып барылды, бакча мәйданын җыештыру уздырылды, чәчәкләрне тәрбияләп үстерү, су сибү – болар барысы да бакча хезмәткәрләре тарафыннан эшләнде. Көзне каршылап участоктан чәчәк орлыклары, яфраклар җыйдык, мәйданны коелган яфраклардан арындырдык. Кышны каршы алганда исә, кардан сыннар ясау, кар көрәү, тубәләрне боздан, кардан арындыру кебек эшләр эшләнде, кошларга җим салыр өчен җимлекләр элдек, аларга җим салуны оештырдык.

Бу эшләр белән бергә бәйрәмнәргә дә зур игътибар бирелде, чөнки милли үзаң, милләткә мәхәббәт хисләренә дә нигез мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә салына. Сентябрьдә мәктәптә үткәрелгән “Белем көне” бәйрәмендә чыгыш ясадык, октябрьдә өлкәннәребезгә багышланган “Әбекәй, бабакай – минем кадерлеләрем” бәйрәме, декабрь аенда Яңа ел бәйрәменә әзерлек барды һәм бик күңелле итеп үткәрдек. Февральдә “Әти белән бергәләп”, мартта “Кояш гомере телим мин әнием сина” бәйрәмнәре үткәрелде. Апрельдә Г. Тукай туган көнен билгеләп үттек. Май ахырында “Сау бул, бакча” бәйрәме уздырылды, анда мәктәпкә укырга барырга тиешле балаларны озату үткәрелде. Май азагында балаларны яклау көненә багышлап “Кече Сабантуй” бәйрәме гөрләп уздырылды.

**Балалар белән “Т.Р. телләр турында законын” тормышка ашыру буенча ике юнәлештә эш алып барыла:**

Татар һәм рус теленә өйрәтү.

Ике телдә дә тиеш дәрәҗәдә тәрбия процессын оештыру.

**Татар һәм рус теленә өйрәтү өч юнәлештә алып барыла.**

**1** Телне өйрәнү.УМК куллану

**2.**Туган як һәм аның табигате белән таныштыру.

**3.**Татар һәм рус халкының мәдәнияте белән таныштыруны дәвам итү.

Балаларның рус телен үзләштерү күрсәткечләре

| | **2018-2019** | **2019-2020** | **2020-2021** |
|---|---|---|---|
| **Югары** | 80% | 67% | 60% |
| **Уртача** | 20% | 33% | 40% |
| **Түбән** | - | - | - |

“От рождения до школы” Н.Е. Веракса, М.А. Васильева, Т.А. Комарова программасының үтәлеше.

| Дәрәҗәләр / Юнәлеш-ләр | Югары | | Уртача | | Түбән | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | **Бала саны** | **%** | **Бала саны** | **%** | **Бала саны** | **%** |
| Танып-белү үсеше | 2 | 51 | 7 | 49 | 0 | 0 |
| Сөйләм үсеше | 3 | 50 | 6 | 50 | 0 | 0 |
| Социаль - коммуникатив үсеш | 3 | 71 | 6 | 29 | 0 | 0 |
| Нәфис - нәфәсәти үсеш | 4 | 52 | 5 | 48 | 0 | 0 |
| Физик үсеш | 5 | 86 | 4 | 14 | 0 | 0 |

Шул ук вакытта төрле дидактик һәм бармак уеннары кулланылды. Бакчада алга киткән технология һәм методларга нигезләнеп һөнәри камиллек үстерү, экологик культура, рухи - әхлакый сыйфатлар тәрбияләү юнәлешендә эш алып барылды. Бу эшләр белән бергә милли һәм бакча традициясенә әйләнгән бәйрәмнәргә дә зур игътибар бирелде, чөнки милли үзаң, милләткә мәхәббәт хисләренә дә нигез мәктәпкәчә белем бирү учреждениеларында салына.

Яңа 2021 - 2022 нче уку елына әзерлек эшләре дә үз югарылыгында алып барылды. Мәктәптә ремонт үтте, стендлар яңартылды.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, шулай ук узган уку елы проблемаларын исәпкә алып **2021-2022 нче уку елына мәктәпкәчә төркемнең методик темасы:**

*ФДББС на туры килгән инновацион технологияләр кулланып, югары сыйфатлы тәрбия-белем бирү процессын тормышка ашыру.*

**2021-2022 уку елына мәктәпкәчә төркемнең максаты:**

Сәламәт, культуралы, яшь үзенчәлекләренә туры килгән белем-күнекмәләр үзләштергән, рус һәм татар телләрен камил белгән, белем алганда ФДББС ын кабул итә алырлык шәхес тәрбияләү.

**2021-2022 уку елына түбәндәге бурычлар билгеләнде:**

1 . Федераль дәүләт белем бирү стандартларын өйрәнеп, белем һәм тәрбия бирүне оештыру. Балаларның физик һәм психик сәламәтлекләрен саклау һәм ныгыту.

2. Уку-укыту медотик кулланмаларына (УМК) таянып, ике дәүләт теле – рус һәм татар телләрен өйрәтүдә яңа алымнар куллану.

3. Педагогның, федераль дәүләт белем бирү стандартларын өйрәнеп, белем һәм тәрбия бирү эшчәнлегендә осталыгын үстерү.

## Педагогик киңәшмәләрдә чыгыш темалары.

1. Тема: “Төркемдә белем һәм тәрбия бирү, балаларның сәламәтлекләрен саклау һәм ныгыту өчен шартлар тудыру.”
2. Тема: Төркемдә ике теллелекне, рус телен өйрәтү буенча эшчәнлек”.
3. Тема: “ФДББС нан чыгып бакча белән гаиләләр арасында хезмәттәшлекне оештыруга бүгенге көн таләпләре”

## Истәлекле даталар һәм күңел ачу чаралары планы.

| Үтәү вакыты | Эшнең эчтәлеге | Эшнең төре | Кем җаваплы |
|---|---|---|---|
| **Сентябрь** | 1.“Белем бәйрәме”<br>2.“Урманчы көне ”<br><br><br>3. Тәрбиячеләр көне | Бәйрәм<br>Урманчы һөнәре белән танышу, презентация карау<br>Җырлы-биюле бәйрәм иртәсе | Тәрбияче |
| **Октябрь** | 1.“Дәү әти – дәү әнием, минем кадерлеләрем” - өлкәннәр көнен билгеләп үтү.<br>2.Мөгаллимнәр көнен билгеләп үтү.<br><br>3. Алтын көз “Сөмбелә”<br>4. Сәламәтлек көне | Әби-бабайларга бәйрәм открыткалары әзерләү<br><br><br>Мәктәпкә экскурсия<br><br><br>Күңел ачу кичәсе<br>Саф һавада спорт уеннары | Тәрбияче<br><br><br><br>Тәрбияче, Тәрбия завучы<br>Тәрбияче<br>Коллектив |
| **Ноябрь** | 1. Халыклар бердәмлеге көне<br><br><br>2. “Көзләрдә дә каршы алабыз әниләрнең бәйрәмен”<br>3.Кыш бабайның туган көне (18 нояб.)<br><br>4.Китап уку көне | Дуслык ярминкәсе (башлангыч сыйныфлар белән берлектә)<br><br>Әниләр катнашында ял итү кичәсе, әниләргә бүләк әзерләү<br>Кыш бабайны котлап хат язып салу, Яңа елбәйрәменә чакыру<br>Китапханәгә бару. | Тәрбияче, башлангыч сыйныф укытучылар ы<br>коллектив<br>Тәрбияче<br><br><br>Тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Декабрь** | 1.Халык уеннары көне.<br>2. Балалар телевидениесы көне.<br><br>3. “Хуш киләсең, Яңа ел!” | Саф һавада уеннар<br>Мультфильмнар төшерү серләре белән танышу(видео карау)<br><br>Бәйрәм кичәсе | Тәрбияче<br>Тәрбияче<br><br>коллектив |
| **Январь** | 1.“Кышкы бакчада!”<br><br>2.Сыйланыгыз кошкайлар<br><br>3.Искечә Яңа ел<br>4.Театр көне. | Фотоконкурс<br><br>Җимлекләр элү<br><br>Күңел ачу, хоровод,<br>Кар бабай белән уеннар<br>Чуар тавык әкиятен сәхнәләштерү. | Тәрбияче, эти-әниләр<br>Әти-әниләр, тәрбияче<br>коллектив<br>Тәрбияче |
| **Февраль** | 1. М.Җәлил тууына 116 ел<br>2. Изгелек эшләү көне<br>3. Туган тел көне<br><br>4. Әти белән көчле мин<br><br>5.Сәламәтлек көне | Шигырьләрен яттан сөйләү<br>Әңгәмә, видео карау<br>Мәктәп китапханәсенә экскурсия<br>Әтиләр катнашында күңелле эстафеталар<br>Чаңгыда йөрү | Тәрбияче<br><br>Тәрбияче<br>Тәрбияче, китапханәче<br>коллектив<br>Тәрбияче |
| **Март** | 1.Песиләр көне<br><br><br>2.Кояш кебек әнием.<br>3.Нәүрүз бәйрәме.<br><br>4.Халыкара театр көне | Йомшак уенчык печи тегү, аны яраткан кешеңә бүләк итү.<br>Музыкаль кичә<br>Карга боткасы пешерү, кышны озату бәйрәме<br>Мәктәп укучылары ярдәмендә әкият сәхнәләштереп нәниләргә күрсәтү | Тәрбияче<br><br><br>Тәрбияче<br>Тәрбияче<br><br>Тәрбияче, башлангыч сыйныф укытучылары |
| **Апрель** | 1.Көлке көне<br><br>2.Балалар китабы көне<br><br>3.Космонавтика көне<br><br>4.Кошлар бәйрәме<br><br>5.Г.Тукай тууга 136 ел . | Күңел ачу кичәсе, клоуннар белән уеннар<br>Китапчык ясау, иҗади эшчәнлек.<br>Ракета ясау, сюжетлы уен уйнау.<br>Сыерчык оялары кую.<br><br>Рәсем күргәзмәсе | Тәрбияче<br><br>Тәрбияче<br><br>Тәрбияче<br><br>Әти-әниләр, тәрбияче<br>Тәрбияче |
| **Май** | 1.Кояш көне (8 май) | Зур Кояш рәсеме ясау, | Тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 2. Җиңү бәйрәменә 77 ел.<br>3.Гаилә көне<br><br><br><br>4.Музейлар көне<br><br><br>5.Хуш, сөекле бакчабыз! | Кояш турында видео карау<br>Һәйкәлгә венок салу.<br><br>Гаилә көне символы буларак кәгазьдән ромашкалар ясап өләшү.<br>Туган якны өйрәнү музеена экскурсия.<br><br>Бәйрәм иртәсе | <br><br>Тәрбияче<br><br>Тәрбияче<br><br><br><br>Тәрбияче, тәрбия завучы<br>Тәрбияче |
| **Июнь** | 1.Балаларны яклау көне<br><br>2.Әйләнә-тирәне саклау көне<br>3.Халыкара дуслар көне<br>4.Әтиләр көне | Сабантуй үткәрү<br><br>Агач утырту<br><br>Дуслык турында әңгәмә<br>Әтиләргә бүләк ясау, котлау | Коллектив<br>Тәрбияче<br><br>Тәрбияче<br>Тәрбияче |

## Мәктәпкәчә төркемнең сәламәтләндерү эшчәнлеген оештыру планы

| № п/п | Эш төре | Үтәлеш | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. Оештыру эшләре | | | |
| 1.1 | Көнлек режимны оештыру һәм күзәтү | даими | тәрбияче |
| 1.2 | Физик тәрбия, “сәламәтлек” папкасын тулыландыру | даими | тәрбияче |
| 1.3 | “Сәламәтлек” көне үткәрү | даими | тәрбияче |
| 1.4 | - яктылык режимын<br>- $t^0$ режимын | даими | кече тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | - һава режимын<br>- юеш җыештыруны үтәү | | |
| 2. Сәламәтләндерү чаралары | | | |
| 2.1 | Балаларны иртән тикшереп кабул итү | даими | тәрбияче |
| 2.2 | Иртәнге гимнастика ясату | даими | тәрбияче |
| 2.3 | Физкультура дәресләре үткәрү | даими | тәрбияче |
| 2.4 | Саф һавада хәрәкәтле уеннар | даими | тәрбияче |
| 2.5 | Һава, кояш ваннасы алу | даими | тәрбияче |
| 2.6 | Су процедуралары үткәрү | даими | тәрбияче |
| 2.7 | Йокыны оештыру | көн саен | тәрбияче |
| 2.8 | Культура-гигиена күнекмәләре бирү | көн саен | тәрбияче |
| 2.9 | Сәламәтләндерү гимнастикасы<br>Коррекция эшләре ( аю табанлылыкны профилактикалау буенча күнегүләр) | даими | тәрбияче |
| 2.10 | Эшчәнлекләр вакытында физкультминуткалар үткәрү | даими | тәрбияче |
| 2.11 | Саф һавада йөрү | даими | тәрбияче |
| 2.12 | Чыныктыру:<br>Су һәм һава белән чыныктыру күнекмәләре бирү | даими | Тәрбияче |
| 3. Дәвалау профилактика эше. | | | |
| 3.1 | Профилактика прививкаларын ясау | план буенча | фельдшер |
| 4. Туклануны оештыру | | | |
| 4.1 | Көнгә 4 ашатуны оештыру | көн саен | директор |
| 4.2 | Ризыкның саклану срогын карау | көн саен | пешекче |
| 4.3 | Туклandыру нормасын үтәү | даими | пешекче |
| 5. Профилактик чаралар | | | |
| 5.1 | Санитар-өйрәтү эше: консультацияләр, әңгәмәләр | даими | тәрбияче |
| 5.2 | Балаларның имгәнүен булдырмау буенча чаралар үткәрү:<br>Куркынычсызлык инструкциясен үтәү<br>Балалар белән әңгәмәләр үткәрү<br>Шөгыльләр үткәрү | даими | тәрбияче |
| 5.3 | Чирләргә профилактик чаралар:<br>- дезинфекцияләү чараларын кулану<br>- санитар режимны саклау<br>-сарымсак һәм суган кулану | даими | коллектив |
| 5.4 | Спортлы күңел ачулар | айга бер | коллектив |

**Балаларның юл-транспорт травматизмын кисәтү буенча профилактик эш.**

| № | Эчтәлек | вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| **Оештыру эшләре** | | | |
| 1. | Балаларның юл-транспорт травматизмын кисәтү буенча мәктәпкәчә төркемнең 2020-2021 уку елына профилактик эш планын төзү. | сентябрь | директор, тәрбияче |
| 2. | Балаларны юл йөрү кагыйдәләренә өйрәтүне оештыру өчен үстерешле тирәлек булдыру | ел дәвамынд | тәрбияче |
| 3. | Әти-әниләр өчен информацион папкалар, стендлар ясау, яңартып тору | ел дәвамынд | тәрбияче |
| 4. | Юл йөрү кагыйдәләре буенча үткәрелгән конкурсларда катнашу. | ел дәвамынд | тәрбияче |
| 5. | “Мин җәяүле” темасына рәсем күргәзмәсе ясау | февраль | тәрбияче |
| 6. | “Юлда булсаң уяу бул!” (велоярыш) | апрель | тәрбияче |
| 7. | Эшкә йомгак ясау | май | директор, тәрбияче |
| **Методик эш** | | | |
| 1. | Вакытлы матбугат һәм әдәбият белән танышып бару | ел дәвамынд | тәрбияче, |
| 2. | Тәрбияче белән инструктаж үткәрү | сентябрь | директор урынбасар |
| 3. | Тәҗрибә уртаклашу (публикация, ачык дәрес) | ел дәвамынд | тәрбияче |
| **Балалар белән эш** | | | |
| 1. | Инструктажлар үткәрү | ел дәвамынд | тәрбияче |
| 2. | Урамда, юлда күзәтүләр оештыру | ел дәвамынд | тәрбияче |
| 3. | Атна саен балалар белән юл йөрү кагыйдәләре буенча эшчәнлек үткәрү. | ел дәвамынд | тәрбияче |

# Методик эш

| № | Эш төре | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 2. | Мәктәпкәчә төркемне яңа уку елына әзерләү. | август | директор |
| 3. | 2020-2021 нче уку елындагы эшчәнлеккә анализ ясау. Бакчаның 2021-2022 нче уку елына эш планын төзү, кабул итү. | август сентябрь | Директор урынбасары тәрбияче |
| 4. | Хезмәткәрләрне тарификация белән таныштыру. | сентябрь | директор |
| 5. | Төркем бүленешен, эшчәнлек челтәрен төзү, раслау. | август | Директор тәрбияче |
| 6. | Семинарларда, утырышларда катнашу. | даими | тәрбияче |
| 7. | Район методик берләшмәсе оештырган конкурсларда катнашу. | план буенча | тәрбияче |
| 8. | Мәктәп белән балалар бакчасы арасындагы дәвамчанлыкны үстерү. | даими | Дир.урынб. тәрбияче, |
| 9. | Экологик тәрбия өчен материалларны туплау, тулыландыру. | ел дәвамында | тәрбияче |
| 10. | Методик почмакны яңа методик әсбәпләр, күрсәтмә материаллар, газета-журналлар белән тулыландырып тору, баету буенча эшләү. | ел дәвамында | директор тәрбияче |
| 11 | Укыту-тәрбия эшен ФДББС на туры китереп алып бару. | ел дәвамында | тәрбияче |
| 12. | Сөйләм үстерү эшчәнлеге өчен уеннарны яңарту, тулыландыру. | январь | тәрбияче |
| 13. | Юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү буенча альбом, кулланма җиһазлар булдыру, тулыландыру. | февраль | тәрбияче |
| 14 | Балаларга рус телен өйрәтүне яңа алымнарга таянып эш алып барырга. | даими | тәрбияче |
| 15. | Сәнгать эшчәнлеге өчен табигый материаллар, күрсәтмә, кулланма җиһазлар туплау. | даими | тәрбияче |
| 16. | Балаларны районыбызның, җирлегебезнең данлыклы шәхесләре белән таныштыру өчен материаллар туплау. | даими | тәрбияче |
| 17. | Дидактик уеннарны яңарту. | даими | тәрбияче |
| 18. | Халкыбыз тарихы – борынгы әйберләр белән таныштыру өчен материаллар туплау, мәктәп музеена экскурсия оештыру. | даими март | тәрбияче, |

# Күргәзмәлекләр

| | Эш төре | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | “Көзге байлык” – яшелчә, җиләк – җимештән күргәзмә | Сентябрь | тәрбияче |
| 2 | Минем кадерлеләрем (Өлкәннәр көненә фотокүргәзмә) | Октябрь | тәрбияче |
| 3 | “Менә нинди минем әни!” Әниләрнең кул эшләре күргәзмәсе | Ноябрь | тәрбияче. |
| 4 | Яңа ел бәйрәменә кулдан ясалган уенчыклар белән бүлмә бизәү | Декабрь | тәрбияче |
| 5 | “Серле кыш ” - кардан сыннар ясау | Январь | тәрбияче |
| 6 | Муса Җәлил шигырләренә ясалган рәсем күргәзмәсе | Февраль | тәрбияче |
| 7 | “Яз, яз җитә”темасына кулдан эшләнмәләр | Март | тәрбияче |
| 8 | Г.Тукай әсәрләрен кисеп ябыштыру, әвәләү аша чагылдырган эшләр күргәзмәсе | Апрель | тәрбияче |
| 9 | Җиңү алып килгән май (стенд ясау) | Май | тәрбияче |

## Алдынгы педагогик тәҗрибәне гомумиләштерү, тарату

| | Эш төре | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Район күләмендә үткәрелгән КМО һәм РМО утырышларында, семинарларда катнашу һәм тәҗрибә уртаклашу, чыгышлар ясау | Даими | тәрбияче |
| 2 | Район, республика күләмендә чыга торган газета журналларга язылу, мәгариф өлкәсендәге яңалыклар белән танышып бару | Даими | директор, тәрбияче, |
| 3 | Тәрбияченең эш тәҗрибәсе буенча китапчыклар ясау, район – республика күләм таратуда матбугат чараларыннан һәм интернеттан файдалану. | Даими | тәрбияче, |

## Әти-әниләр белән эш планы

| ай | атна | Эш төре |
|---|---|---|
| сентябрь | 1нче атна | Ата-аналар почмагын тәртипкә китерү, җыелышка кирәкле мәгълүматны әзерләү |
| | 1нче атна | “Без инде зурлар” темасына ата-аналар белән әңгәмә үткәрү |
| | 1нче атна | “ Баланың сөйләме” темасына консультация. |
| | 1-2 нче атна | “Гомуми тәкъдимнәр”, “Тышкы кыяфәткә таләпләр” темаларына һәр ата-анага кушымталар өләшү |
| | Ай дәвамында | “Ни өчен бала бакчага барырга теләми”, “Өйдә балаларның үз-үзләрен карау күнекмәләрен тәрбияләү”, “Гаиләдә мактау һәм шелтәләү”, “Баланың көйсезләнүенә ничек карарга” темаларына һәр ата-ана белән индивидуаль әңгәмә |
| | 3нче атна | “Баланы ничек мөстәкыйль киенергә өйрәтергә”, “Шәхси гигиена күнекмәләре һәм аларның бала үсешендәге урыны” темаларына консультация |
| | 4 нче атна | Консультацияләр: “Тәмле теллелек турында нинди әдәби әсәрләр укырга мөмкин?”  “Үзеңнең ниндилегеңне беләсең килсә, балаңа кара” |
| окт ябр | 1 нче атна | “Тел һәм аның йорты белән танышу” – балаларга артикуляцон гимнастика  (киңәшләр) |

| | | |
|---|---|---|
| | 1 нче атна | Консультацияләр: Өлкәннәр көненә фотокүргәзмә ясау ”Минем кадерлеләрем” |
| | 2 нче атна | Консультация: “Гафу итәргә өйрәнәбез”<br>Бакча өчен үз вакытында түләү кагыйдәләре турында һәр ата-ана белән әңгәмә |
| | 2 нче атна | “Бармак уеннары белән танышу” –(киңәшләр) |
| | Ай дәвамында | “Балаларга нәрсә укырга”, “Дөрес итеп сөйләшергә өйрәнәбез” темаларына консультация |
| | 4 нче атна | “Көз бәйрәмен” үткәрү |
| ноябрь | Ай дәвамында | “Балаларны халык аваз иҗатына нигезләнеп тәрбияләү”, “Вак моториканы үстерү” темаларына һәр ата-ана белән индивидуаль әңгәмә |
| | 2 нче атна | “Бармак уеннары ярдәмендә телне шомартабыз” практик киңәшләр |
| | 2 нче атна | Консультация “Спорт белән шөгыльләнәбез ” |
| | 2 нче атна | “Бала яңа сүзләр өйрәнә” әңгәмә |
| | 3 нче атна | Чыныктыру чараларын үткәрү һәм аларның әһәмияте темасына фикер алышу |
| | 3нче атна | “Бала нәрсә белән кызыксына? ” тематик әңгәмә |
| | 4 нче атна | Саф һавада ата-аналар белән берлектә спорт бәйрәме үткәрү |
| декабрь | 1 нче атна | “Тиздән кышкы бәйрәмнәр” – күчмә-папка ясау |
| | 2 нче атна | “Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның үсешендә уенның роле” темасына ата-аналар җыелышы. |
| | Ай дәвамында | “Бала тыңламаса нишләргә”, “Баланың үз-үзенә йомылуы” темаларына һәр ата-ана белән индивидуаль әңгәмә. |
| | 1-2 нче атна | Баланы бакчага вакытында алып килү, бакча өчен вакытында түләү турында һәр ата-ана белән индивидуаль әңгәмә |
| | 3 нче атны | “Кышкы уеннар”, “Кышкы бәйрәмнәрне каршылыйбыз”-тематик әңгәмә |
| | 3 нче атна | Комитет белән бәйрәмне үткәүгә әзерлек турында сөйләшү. |
| | 4 нче атна | “Бала белән дөрес сөйләшү”, “Баланың тормышын һәм сәламәтлеген саклау” кушымталар өләшү |
| | 4 нче атна | Кыш бәйрәмен үткәрү |
| | 4 нче атна | “Өйдә нинди сөйләм үстерү уеннары уйнарга кирәк” темаларына һәр ата-ана белән индивидуаль әңгәмә |
| январь | 1 нче атна | “Телевидение һәм кечкенә балалар психикасы”, “Баланың куркуы” темаларына һәр ата-ана белән индивидуаль әңгәмә |

| | | |
|---|---|---|
| | Ай дәвамында | “4-5 яшьлек балаларның үсеш үзенчәлекләре”, “Үзсүзлелек һәм киреләнү” темаларына консультация Консультацияләр: “Кешенең кешелеге сүз белән түгел, эш белән” |
| | 2 нче атна | Мәйданчыкта кардан корылмалар төзү |
| | 2 нче атна | “Рәсем буенча хикәя төзү, сөйләм үстерү” консультация |
| | 3 нче атна | “Бала үсешенә ата-аналар куйган таләпләрнең тәэсире” күчмә-папка |
| | 4 нче атна | “Әти, әни һәм мин – без тату гаилә” (әңгәмә) |
| февраль | Ай дәвамында | “Гафу итәргә өйрәнәбез”, “Гаиләдә кем баш, яки тәрбиядәге ялгышлар” темаларына һәр ата-ана белән индивидуаль әңгәмә |
| | | Консультацияләр<br>“Мактау һәм мактану, алар тәрбия эшендә кирәкме?” |
| | | Баланы мактарга кирәкме?” |
| | 3 нче атна | Баланы бакчага вакытында алып килү, бакча өчен вакытында түләргә кирәклеге турында һәр ата-ана белән индивидуаль әңгәмә |
| | 3-4 нче атна | “Ата-ана булу осталыгы “ тематик әңгәмә |
| | 3 нче атна | “Китап – иң яхшы дус һәм ярдәмче” темасына консультация |
| | 3 нче атна | “Табышмакка җавап табарга өйрәнү” индивидуаль әңгәмә |
| | 4 нче атна | “Яссы табанлыкны булдырмау чаралары”, “Игътибар, урам!” кушымталар әзерләү |
| | 4 нче атна | Әтиләребезгә бүләк әзерләү |
| март | 1 нче атна | Комитет белән Әниләр бәйрәменә әзерлекне сөйләшү |
| | 1 нче атна | “Әниләр һәм әбиләр бәйрәме” үткәрү |
| | 1 нче атна | “Сөйләм уеннарының әһәмияте” үткәрү |
| | 1-2 нче атна | “ОРЗны булдырмау чаралары”, “Файдалы үләннәр” кушымталар әзерләү |
| | Ай дәвамында | “Балаларга телевизор карауда булган таләпләр” һәр ата-ана белән индивидуаль әңгәмә<br>Консультацияләр:<br>“Юмарт булу серләре”<br>Юмарт булу турында шәхси киңәшләр |
| | 1-2 нче атна | Баланы бакчага вакытында алып килү, вакытында түләргә кирәклеге турында һәр ата-ана белән индивидуаль әңгәмә |
| | 3 нче атна | “Балаларга сәламәтлекләрен ныгытырга ярдәм итегез” темасына консультация |
| | 3 нче атна | “Телевизион бәйлелек” тест үткәрү |
| | 4 нче атна | Ата –ана белән бала арасындагы каршылыклар һәм аларны хәл итү юллары. |

| | | |
|---|---|---|
| апрель | 1 нче атна | Космоска багышланган рәсемнәр күргәзмәсе |
| | 1 нче атна | “Эш арасында уеннар” кушымталар әзерләү |
| | Ай дәвамында | Консультацияләр: “Әләкчене ничек тәрбияләргә” “Кайсы начаррак әйтми калумы, әллә инде әләкләүме? – сораштыру үткәрү |
| | 2 нче атна | “Дөрес итеп сөйләшергә һәм суларга өйрәнәбез” темаларына консультация темасына консультация |
| | 1-3 нче атна | “Баланы шәхес итеп үстерүдә сюжетлы – рольле уеннарның файдасы” темасына консультация |
| | 4 нче атна | “Бала тормышында уен һәм уенчыклар” анкета – сорауалу |
| май | 1 нче атна | Җиңү бәйрәме үткәрү |
| | Ай дәвамында | “Уен формасында чыныктыру”, “Бала үсешендә хәрәкәтле уеннарның роле” темаларына консультация |
| | 2-3 нче атна | “Бала уенда нәрсәгә өйрәнә”, “Балага нинди уенчыклар кирәк”, “Таныш булмаган кешеләр белән аралашу күнекмәләре” кушымталар әзерләү |
| | 2 нче атна | “Бала үсешендә сөйләм уеннарның роле” темаларына консультация |
| | 3-4нче атна | “Бергәләп уенчык ясыйбыз” һәр ата-ана белән индивидуаль әңгәмә |
| | 4 нче атна | “Хуш бакча!” бәйрәменә әзерләнү. |
| | | Еллык эшчәнлеккә презентация ясау |
| | | Ачык чараларга чакыру |
| | | Әти –әниләр өчен анкета үткәрү |